КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 3 июнь г.Казань № 766

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм турында» 2025 ел, 14 июль, 515 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм турында» 2025 ел, 14 июль, 515 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 16 октябрь, 834 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «халкы 50 меңгә кадәр» сүзләрен «яшәүчеләре 50 мең кешегә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «халкы» сүзен «яшәүчеләре» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын түбәндәгеләр буенча вәкаләтле республика башкарма хакимият органы итеп билгеләргә:

муниципаль учреждениеләрдә, расланган һөнәри квалификация төркемнәреннән һәм эшчеләр һөнәрләрен һәм хезмәткәрләр вазыйфаларын һөнәри төркемнәргә кертү критерийларыннан файдаланып, Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеге («Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация

тасвирнамәләре» һәм «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» бүлекләре), шулай ук һөнәри стандартлар реестры (һөнәри эшчәнлек төрләре исемлеге) нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы яисә җирле үзидарә органы карамагындагы, шул исәптән аларның структур һәм аерымланган бүлекчәләре мәдәният оешмаларында мәдәният хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлеген раслау буенча;

бер мәртәбә компенсация түләү алуга мәдәният хезмәткәрләрен сайлап алуга таләпләрне билгели торган норматив хокукый актны раслау буенча (шул исәптән бер мәртәбә компенсация түләү алуга сайлап алу критерийлары);

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга яисә яшәүчеләре саны 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшкә килгән (күченгән) мәдәният хезмәткәрләрен бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре алуга сайлап алу буенча;

югары белем бирү оешмасында яисә һөнәри белем бирү оешмасында укуны тәмамлау елында мәдәният хезмәткәренә үзе яшәгән урында (авыл торак пунктында, йә эшчеләр бистәсендә, йә шәһәр тибындагы поселокта, йә яшәүчеләре саны 50 мең кешегә кадәр булган шәһәрдә) урнашкан мәдәният оешмасына эшкә урнашканда бер мәртәбә компенсация түләүе бирү турында карар кабул итү буенча;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, эшчеләр поселокларына, шәһәр тибындагы поселокларга, яшәүчеләре 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү буенча.»;

3 пунктта «халкы» сүзен «яшәүчеләре» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә халкы 50 меңгә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибендә:

исемендә «халкы 50 меңгә кадәр» сүзләрен «яшәүчеләре 50 мең кешегә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы карары белән расланган «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының 37 нче кушымтасында бирелгән Россия Федерациясенең халкы 50 мең кешегә кадәр булган торак пунктларына килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яшәүчеләре саны 50 мең кешегә кадәр булган шәһәрләргә эшләр өчен килгән (күченеп килгән) мәдәният тармагы хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен (алга таба шул ук эзлеклелектә – мәдәният хезмәткәрләре, бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве түбәндәге мәдәният хезмәткәрләренә бирелә:

югары белемле яисә урта һөнәри белемле Россия Федерациясе гражданнары булган;

агымдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча бер мәртәбә компенсация түләү алуга мәдәният хезмәткәрләрен сайлап алу йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы карамагындагы мәдәният оешмасы (алга таба – Министрлык) белән Россия Федерациясенең хезмәт законнары нигезендә билгеләнгән тулы эш көне һәм, расланган һөнәри квалификация төркемнәреннән һәм эшчеләр һөнәрләрен һәм хезмәткәрләр вазыйфаларын һөнәри төркемнәргә кертү критерийларыннан файдаланып, Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеге («Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» һәм «Мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация тасвирнамәләре» бүлекләре), шулай ук һөнәри стандартлар реестры (һөнәри эшчәнлек төрләре исемлеге) нигезендә төзелгән, Мәдәният министрлыгы тарафыннан расланган мәдәният хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфада хезмәт функцияләрен башкару шартларында хезмәт шартнамәсен (алга таба шул ук эзлеклелектә – хезмәт шартнамәсе, вакантлы вазыйфалар исемлеге, мәдәният оешмасы, муниципаль берәмлек) төзегән;

Министрлык белән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзегән.

Әлеге Тәртиптә мәдәният оешмалары дигәндә мәдәният оешмалары, шулай ук «балалар сынлы сәнгать мәктәбе», «балалар музыка мәктәбе», «балалар хор мәктәбе», «балалар сәнгать мәктәбе», «балалар хореография мәктәбе», «балалар театр мәктәбе», «балалар цирк мәктәбе», «балалар сәнгать һөнәрләре мәктәбе» дигән махсус атамалы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә һөнәри белем бирү оешмалары, шул исәптән аларның гамәлгә куючылары Министрлык яисә муниципаль берәмлек булган структур һәм аерымланган бүлекчәләре аңлашыла.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Министрлык бер тапкыр бирелә торган компенсация түләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 10 эш көне эчендә килешүнең ике нөсхәсен имзалый һәм аларны имзалау өчен мәдәният хезмәткәренә җибәрә.

Мәдәният хезмәткәре шартнамәнең ике нөсхәсен алган көннән алып өч эш көне эчендә аларны имзалый һәм имза салынганнан соң өч эш көне эчендә шартнамәнең бер нөсхәсен Министрлыкка кайтара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин